## Файдалы киңәшләр



Кар сулары ага. Н. Туганов фотосы.

# Яз һәм сипкелләр

Яз кояшы җиргә карап елмаюга, шаян нурлар кызлар күзләргә керешә. Сөйкемле итик әле үзләрен дип, алсу йөзләренә кояштай балкып торган бөрчекләр сибә. Тик кызлар нурлар наянлыгы белән килешергә теләми. Март, апрель айлары җиттеме, редакциягә, сипкелләрдән котылу юлларын өйрәтсәгез иде, дигән үтенеч тулы хатлар юллана башлый.

Безгә калса, сипкел ул яшьлек билгесе. Шулай да, кызларның үтенечен егып булмый. Аңлап торабыз, гүзәллеккә омтылалар, тагын да матуррак буласылары килә. Шуны искә алып, борынгыдан калган сер капчыгын бергәләп чишик. Игътибар итегез, карт әниләребез фәкать үсемлекләрне файдаланган. Шуңа да тәкъдим ителәсе рецептлар кызларыбызның табигый матурлыгын сакларга ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

1. Бер учма петрушка үләнен ярты литр суга салып ярты сәгать кайнатыгыз. Сөзгәннән соң аның белән иртәле-кичле битегезне сөртегез. Бу төнәтмә сипкелләрне төссезләндерү белән бергә, бит тиресен сафландыра, кызыл таплар калкуны, җыерчыклар артуны кисәтә.

2. Башлы суган согы да сипкелләрне киметергә булышлык итә.

3. Сөтлегән үләне суты өзеп алгач та бит тиресенә сөртелә һәм аның өстеннән шунда ук балык мае сөртеп куела. Бераздан бит тиресенең нечкә өлеше катлам-катлам булып кубып төшә. Шуннан соң бит сипкел һәм таплардан арынып, чистарып кла. Балык мае исә бит тиресен сөтлегән үләненең зәһәр согы тәэсиреннән саклый.

4. Биш грамм саф глицерин, 15 грамм лимон согы һәм 25 грамм кайнаган суны бергә кушып, яхшылап болгатыла. Алынган сыекча биткә сөртелә, ун минуттан соң ул юып алына. Шуның артыннан биткә тукландыру кремы сөртеп куела.



Яз көне биткә маскалар ясау һәр хатын-кыз өчен файдалы. Аларның берсе түбәндәгечә эшләнә: бер чәй кашыгы сөт, шул кадәр үк бал һәм бер йомырка сарысы белән катнашма ясагыз. Бит тиресенә крем сөрткәннән соң әлеге катнашманы биткә ягып, 15—20 минут ятып торыгыз. Юынуга үзегезне яшәреп киткәндәй хис итәрсез.

СЕРДӘШ.

# Онытылган ризыклар

БАШ-АЯК БӘЛЕШЕ

Төче камыр басып, кечерәк һәм зуррак ике кисәккә бүләләр. Зуррагын ярты сантиметр калынлыгында җәяләр һәм майлаган табага салалар. Шунда бәлеш эчлеген салып, өстенә камырның кечерәк кисәген җәеп каплыйлар, кырыйлары чеметеп ябыштырыла. Өстенә шулпа салу өчен тишек калдыралар һәм аны камыр белән түгәрәк ясап бөкелиләр.

Бәлешне 1,5—2 сәгатькә мичкә, яисә духовкага куялар. Бөкесен алып шулпа өстәгәч, яңадан мичкә тыгалар. Өсте кибеп, көеп китмәсен өчен, аны юеш кәгазь белән, яисә борынгыча арыш камырын җәеп каплыйлар.

Әзер бәлешне табынга табасы белән кайнар килеш чыгаралар.

ТОМАЛАП ПЕШЕРГӘН

КАРТА. Яхшылап эшкәрткән картаны тозлы суда пешереп алалар да, салкын суда әйбәтләп югач, шакмаклап турыйлар. Аннары чуенга салып, вак кына тураган башлы суган, эре итеп туралган бәрәңге, кишер, ит шулпасы өстәп, тоз сибеп, өстен нык итеп ябалар да мичтә яисә плитәдә томалап пешерәләр.

Пешкән картаны болгаталар һәм кайнар килеш тәлинкәләргә салып бирәләр. Катыкны аерым куялар.

## СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ?

Фин медиклары исәпләвенчә, түбәндәге җиде кагыйдәне даими үтәсәң, тормышыңны ким дигәндә тагын 10 елга озайта аласың икән:

1. Тәмәке тартмаска (тартмаучылар арасында рактан һәм инфарктан үлүчеләр саны шактый ким).

2. Алкоголь кулланмаска яки бик аз күләмдә генә эчәргә.

3. Гәүдә авырлыгын нормада тотарга (симез кешеләр арасында үлүчеләр саны тиешле авырлыктагыларга караганда бер ярымга артыграк).

4. Физик активлыкны сакларга.

5. Иртәнге ашны һәрчак ашарга.

6. Билгеле бер сәгатьләрдә генә ашарга, шулар арасында капкалап алу белән шөгыльләнмәскә.

7. Тәүлегенә, ким дигәндә, 7 сәгать йокларга.

В. ШЕВКИН.
(«Кичке Ташкент»).

Саесканнар кар өстендә йөрсә көннәр җылыта башлый.

Кыр үрдәкләре җылы яклардан кайтканда симез булса, яз салкын булачак.

Апрель артык җылы булса, май салкын, җиллеяңгырлы булачак.

Бозбармак (сосульки) озын булса, яз дәвамлы килә.

Беренче күк күкрәү көннәр җылыта башлауга булыр.

Беренче күк күкрәү кыйбла ягыннан булса, иген уңар.

Боз төнлә китсә, шулай ук иген уңар.

## Күзәтегез, сынагыз...

Яз эретми, озак туңдырып торса, җәй коры булыр.

Яз иртә килсә, иген уңар.

Яз елгаларда су артмаса, иген уңмас.

Аккош иртә килсә, яз озак торыр.

Ала карга агач башына кунса, яз тиз килер, җиргә кунса, озак килер.

Карга җылы яктан килгәч агач башына кунса, ел туклыклы булыр.

Карга карда коенса, көн бозылыр.

Торна иртә килсә, көннәр тиз җылытыр.

Яз тавык әтәч булып кычкырса, ел авыр булыр.

Сыерчыктан элек тургай килсә, туклык булыр.

Ат карга ятса, җылыга тарта.

Мал кайсы якка аркасын куеп ятса, шул яктан җил көт.

Эт карда аунаса, көн аязыр.

Кошлар оясын агачның көньягына корса, җәй салкын килер.

Куяннар йонын озак алмаштырмый йөрсә, яз суык килер.

# КАВЫН, КЫЯР ҮСТЕРИМ ДИСӘҢ

Алрель бакчачы өчен иң мәшәкатьле ай. Ел уңышы бакчачының шушы айдагы фидакарь эшләвенә дә бәйле. Апрельдә җимеш агачлары формалаштырыла, агачка агач ялгана, кар басымы астында каерылып төшкән ботаклар үз урынына тартып бәйләнә. Җимеш агачларындагы, җиләк куакларындагы сынган, корыган, авыру ботаклар кисеп алып яндырыла. Җиләк-җимеш куаклары тукландырыла, корткычларга, төрле авыруларга каршы көрәш җәелдерелә. Җир өлгерү белән туфрак эшкәртелә. Кыскасы, бакчада эшләр күп, санап бетерерлек түгел. Яшелчә үстерүчеләргә дә олы мәшәкатьле бу ай. Төп сүз —яшелчә үсентеләре үстерү турында.

Безнең шартларда тәрәзә төбендә яки теплицаларда (ачык һавага күчереп утыртканчы) помидор—60—65, болгар борычы —65—70, иртә кәбестә—55—60, кыяр, карбыз, кавын үсентеләре 25—30 көн үсәргә тиеш.

Тәрәзә төбендә үскән үсентеләр майның уннарында пленка астына күчереп утыртыла.

Апрель уртасында кыяр-карбыз, кавын орлыгы чәчелә. Безнең шартларда карбызның «Огонек», кавынын «Колхозник» сортлары яхшы өлгерә һәм әйбәт уңыш бирә. Мәсәлән, без республиканың төньяк өлешендәге югарыда күрсәтелгән культуралар орлыгын 14 нче апрельдә чәчтек. Май аеның тәүге ун көнендә пленка астына күчердек. Пленка астында үсте. Карбыз—унбишеннән, кавын—20 июльдән өлгерә башлады. Тәмнәре ягыннан Үзбәкстанда үскәннән калышырлык булмады.

—Бөтен шартын китереп тозласам да, кыярым бозылган, кабыгы гына торып калган, үзе суга әйләнгән,—дип зарланган хуҗабикәләрне еш очратырга туры килә. Моның сәбәбе, кирәкле сортларны сайлап ала белмәүдә.

Безнең шартларда кыярның «Муромский-36»,«Вязниковский-37», «Урожайный-88,» сортлары яраклаштырылган. «Муромский-36» сортлы кыяр иртә өлгерә, шытып чыкканнан соң 35—40 көн дигәндә аны ашый башлыйсың. Тик ул кышка тозларга яраксыз. Шуның өчен бу сортны җәй ашау өчен генә чәчәргә кирәк.

«Вязниковский-37» сорты тәме белән аерылып тора. Ул «Муромский-36» сортына караганда 10—12 көнгә соңрак өлгерә. Тозларга яраклы, озак саклана. Кыяры саргаймый.

«Неженский» сорты соң өлгерә, тозлау өчен иң әйбәт сорт. Әйе, сортларның тәмендә дә, аның уңышында да, кышкылыкка саклау ягынан да зур аермалыклар бар.

Кайбер елны шулай да була. Түтәл тутырып кыяр утыртабыз. Кызганычка каршы, үсентеле кысыр чәчәкләр сырып ала, кыяры аз була. Моны өлгереп җитмәгән орлык чәчүдән күрәм мин. Шуңа күрә өлгергән, тулы орлыкларны гына чәчәргә кирәк.

Чәчәр алдынан аны тикшереп карарга мөмкин: орлыкны өч процентлы тозлы суга салсаң, өлгермәгән буш орлык өскә калкып чыга, ә өлгергән тулы орлыклар төпкә төшә.

Карбыз, кавын,кыяр үсентеләре күчереп утыртуны яратмый. Шуңа күрә орлыкларны махсус кубикларга, баетылган туфрак тутырылган стаканнарга чәчәргә кирә.

Махсус кубиклар магазиннарда сатыла. Ул булмаса, стаканнарны кәгазьдән дә ясарга була. Моның өчен 16 сантиметр киңлегендә, 25 сантиметр озынлыгында газета бите кисеп алына. Ярты литрлы шешәгә урала, төбе бөгелеп куела һәм ябыштырыла. Стакан әзер. Аның эченә баетылган туфрак тутырыла.

Моның өчен чирәм җирдән кара туфрак алына, аңа бергә бер исәбеннән черемә кушыла, бер чиләк исәбеннән бер стакан агач көле кушыла, компонентлар ныклап аралаштырыла. Стаканнар төбенә 5—6 сантиметр калынлыгында туфрак салына һәм алар әрҗәгә тезеп утыртыла. Шуннан соң орлыкны төртеп чыгасы гына кала. Ул пленка астына күчереп утыртканга тикле 25—30 көн элек чәчелә. Димәк, кыярны стаканнарга апрельнең 5 еннән унына кадәр утыртырга кирәк.

Югарыда күрсәтелгән культуралар барысы да җылыны ярата. Аларга иркенләп үсү өчен иң һәйбәт җылылык 24—26 градус булырга тиеш. Үсентеләргә фәкать җылы су гына сибелүен дә истән чыгармагыз. Туфрак артык дымлы да, коры да булмасын.

Үсентеләр тәрәзә төбендә, яки теплицаларда үскәндә ике мәртәбә тукландырыла. Алар яңа сыер тизәгенә бермә-бер су кушып, ул булмаганда 1 чиләк суга мочевина—5,суперфосфат—15, хлорлы калий—15 грамм салып эретелә һәм тукландырыла.

Яз иртә килгән елны апрель урталарында ук туфрак өлгерә башлый. Аның өлгерүен белү өчен үз участогыгыздагы туфракны учыгызга салып кысып карагыз. Бармак



араларыгыздан су сыгылып чыкмаса, туфрак эшкәртергә ярый дигән сүз.

Туфрак өлгергәч тә кичекмәстән ашлама кертеп, җирне эшкәртеп, иртә культураларны чәчә башлау мотлак. Иртә культураларга яшел суган, кишер, редиска, салат, борчак, петрушка кебек яшелчә керә. Туфрак җылынуга аш чөгендере чәчелә. Орлыклар тизрәк шытып чыксын өчен, түтәлләр пленка белән каплап куела. Орлык шытып чыккач та пленка алына.

Бакча культураларын иртә утыртсагыз, уңыш югары булыр, иртә өлгерер. Үсентеләрне ачык һавага күчереп утырту турында сүзне май аенда дәвам итәчәкбез.

С. ХАҖИЕВ,
агроном.

